РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

27.06.2022г. №11

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең 12.11.2021 елда кабул ителгән №28 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибен раслау турында карарына үзгәреш кертү

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 26 статьясы нигезендә, коррупциоген нормаларны бетерү максатларында, Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең 12.11.2021 елда кабул ителгән №28 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибен раслау турында” карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Статья 16. Инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу.

1. Конкурс сайлап алуны комиссия башкара.
2. Конкурс сайлап алу критерийлары, аларның әһәмияте, аларга тиешле баллар һәм үлчәү коэффициентлары 1 нче кушымтада (алга таба – критерийлар) билгеләнгән.
3. Конкурс сайлап алу әлеге Тәртипнең 14 статьясы нигезендә үткәрелә торган комиссия утырышында башкарыла.
4. Комиссия инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны узган инициативалы проектларны ачыклау критерийлары нигезендә бәяләүне гамәлгә ашыра.
5. Конкурс нәтиҗәләре буенча йомгаклау бәясен исәпкә алып, комиссия инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны узган яисә узмаган дип игълан итү турында карар кабул итә.
6. Барлык критерийлар буенча максималь суммалы балл җыйган конкурс сайлап алуын узган инициатив проект игълан ителә.».

1.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау

Тәртибенә 1 нче кушымта нигезендә әлеге карарга кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Д.М.Гайнутдинов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының
Иштуган авыл җирлеге
Советының 27.06.2022 елдагы
№11 карарына
1 номерлы кушымта

**Конкурс сайлап алу критерийлары**

<table>
<tr><th>N<br>т/б</th><th>Критерий исеме</th><th>Критерий буенча баллар</th></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Актуаль (кискен) проблемалар</td></tr>
<tr><td colspan="2">бик югары - проблема халык тарафыннан критик дип бәяләнә, проблеманы хәл итү халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү һәм саклау өчен кирәк</td><td>10</td></tr>
<tr><td colspan="2">югары - проблема халык тарафыннан шактый бәяләнә, аны хәл итмәү тормыш сыйфатына тискәре йогынты ясаячак</td><td>7</td></tr>
<tr><td colspan="2">уртача - хезмәт проблемасы халык тарафыннан актуаль дип бәяләнә, аны хәл итү тормыш сыйфатын яхшыртуга китерергә мөмкин</td><td>4</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="2">Проектны тормышка ашыруга комплекслы якын килү</td></tr>
<tr><td colspan="2">әйе</td><td>10</td></tr>
<tr><td colspan="2">юк</td><td>0</td></tr>
<tr><td>3</td><td colspan="2">Халыкның аз керемле төркемнәре өчен инициативалы проектның җайлашуы</td></tr>
<tr><td colspan="2">әйе</td><td>10</td></tr>
<tr><td colspan="2">юк</td><td>0</td></tr>
<tr><td>4</td><td colspan="2">Количество граждан, поддержавших инициативный проект</td></tr>
<tr><td colspan="2">500дән артык кеше</td><td>10</td></tr>
<tr><td colspan="2">250 дән 500 гә кадәр кеше</td><td>7</td></tr>
<tr><td colspan="2">50дән 250 гә кадәр кеше</td><td>5</td></tr>
<tr><td colspan="2">50гә кадәр кеше</td><td>3</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| 5 | **Инициативалы проект нәтиҗәләрен карап тоту (саклап калу) максатларында киләсе чорларда бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру зарурилыгы** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| 6 | **Оригинальлек, креативлык** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| 7 | **Инновацион технологияләр, яңа техник карарлар куллану** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| 8 | **Гаризада презентацион материаллар, дизайн-проект булу** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| 9 | **Инициативалы проектны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда җәмәгатьчелекнең катнашуы** | |
| 9.1 | **Инициативалы проектның гомуми бәясеннән инициативалы түләүләр өлеше** | |
| | инициативалы проектның гомуми бәясенең 20% нан | 10 |
| | инициативалы проектның гомуми бәясенең 15% тан 20 % ка кадәр | 8 |
| | инициативалы проектның гомуми бәясенең 10% тан 15 % ка кадәр | 5 |
| | инициативалы проектның гомуми бәясенең 0% тан 10% ка кадәр | 1 |
| 9.2 | **Инициативалы проектны тормышка ашыруда мөлкәт һәм (яки) хезмәт катнашуы** | |
| | әйе | 5 |
| | юк | 0 |